Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр

Боерган  авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына мәгълүмати материаллар исемлеге:

1) шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы. Территориаль зоналар.

2) территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар чикләре картасы.

3) җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен куллану тәртибе һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү.

4) кушымта. Территориаль зоналарның чикләре турында белешмәләр.

Боерган  авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары .

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект экспозициясен ачу урыны һәм датасы:

Татарстан Республикасы, Буа районы, Чуаш Сарыкамышы авылы, Совет урамы, ФАП янында 21а бинасы.

Боерган авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты экспозициясен үткәрү сроклары :

Экспозицияне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат : 19.11.2024 елдан 03.12.2024 елга кадәр 8: 00 дән 16:00 гә кадәр.

Гавами тыңлауларда катнашучыларның Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектына кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:

Фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр язма рәвештә, шулай ук чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин: ТР, Буа муниципаль районы, Боерган авылы, Ленин ур., 43 нче бина (эш көннәрендә - 8.00 дән 17.00 гә кадәр). Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты - 02.12.2024 ел. Тәкъдимнәр һәм искәрмәләр шулай ук гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын уздырган вакытта язма рәвештә яисә телдән бирелергә мөмкин.

Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Боерган авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү 2024 елның «03» декабрендә  9:30 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Буа районы, Чуаш Сарыкамышы авылы, Совет урамы, ФАП янында 21а бинасы. адресы буенча билгеләнде.

Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат һәм аңа мәгълүмати материаллар:

Буа муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://buinsk.tatarstan.ru .

Әлеге хәбәрнамәне бастырып чыгарырга:

Буа муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://buinsk.tatarstan.ru

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Боерган авыл җирлеге башлыгы : И.В.Малышева